КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 5 апрель г.Казань № 415

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясендә мәгълүмат технологияләре һәм югары технологияләр индустриясен сыйфатлы үстерүгә ярдәм итә торган Иннополис шәһәрендә уникаль экосистема төзүгә юнәлдерелгән эшчәнлекнең устав төрләрен гамәлгә ашыруга чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 3 июль, 535 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 18 август, 745 нче; 2022 ел, 29 август, 918 нче карарлары белән кертелгән үзшәрешләрне исәпкә алып) расланган Россия Федерациясендә мәгълүмат технологияләре һәм югары технологияләр индустриясен сыйфатлы үстерүгә ярдәм итә торган Иннополис шәһәрендә уникаль экосистема төзүгә юнәлдерелгән эшчәнлекнең устав төрләрен гамәлгә ашыруга чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Субсидияләр турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

7 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлап алуны үткәрү срокларын, заявкалар бирелә башлау яки кабул итү тәмамлану датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән иртәрәк була алмый);»;

8 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик заты капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;»;

9 пунктта:

бишенче абзацта «сайлап алуны үткәрү турында игълан урнаштырылган айга кадәрге айның беренче көненә карата» сүзләрен төшереп калдырырга;

унынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«коммерциягә карамаган оешма офшор компаниясе, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормый;»;

15 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәләренең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәгълүмат технологияләре, цифрлы икътисад һәм (яки) робототехника өлкәсендә семинарлар, конференцияләр, форумнар, олимпиадалар, интеллектуаль конкурслар һәм башка чаралар оештыруга һәм үткәрүгә бәйле, шулай ук Татарстан Республикасы командаларының әлеге чараларда катнашуын тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 3 июль, 540 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 29 август, 918 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Мәгълүмат технологияләре, цифрлы икътисад һәм (яки) робототехника өлкәсендә семинарлар, конференцияләр, форумнар, олимпиадалар, интеллектуаль конкурслар һәм башка чаралар оештыруга һәм үткәрүгә бәйле, шулай ук Татарстан Республикасы

командаларының әлеге чараларда катнашуын тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Субсидияләр турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

7 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлап алуны үткәрү срокларын, заявкалар бирелә башлау яки кабул итү тәмамлану датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән иртәрәк була алмый);»;

8 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик заты капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;»;

9 пунктта:

алтынчы абзацта «айның 1нче көненә карата» сүзләрен «айдан иртәрәк булмаган вакытка карата» сүзләренә алмаштырырга;

унынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган айга кадәрге айның 1 нче көненә коммерциягә карамаган оешманың офшор компаниясе, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры (яки) турыдан-туры булмаган (өченче зат аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмавын раслый торган, коммерциягә карамаган оешма җитәкчесе тарафыннан кул куелган

гарантия хаты;»;

15 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәләренең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);».

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затларның махсуслаштырылган торак урыннарны наемга алу шартнамәләре буенча ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, алар арасындагы затларга бирелә торган торак урыннарга милек хокукын дәүләт теркәвенә алуны рәсмиләштерүгә бәйле чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 27 июль, 660 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 29 август, 918 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Юридик затларның махсуслаштырылган торак урыннарны наемга алу шартнамәләре буенча ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, алар арасындагы затларга бирелә торган торак урыннарга милек хокукын дәүләт теркәвенә алуны рәсмиләштерүгә бәйле чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Субсидияләр турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, бердәм порталда «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

8 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлап алуны үткәрү срокларын, заявкалар бирелә башлау яки кабул итү тәмамлану датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән иртәрәк була алмый);»;

9 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлап алуда катнашучы чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмау. Офшор компанияләренең Россия юридик заты капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында

катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;»;

11 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлап алуда катнашучының офшор компаниясе, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмавын раслый торган, сайлап алуда катнашучының җитәкчесе яисә башка вәкаләтле заты тарафыннан кул куелган гарантия хаты;»;

20 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәләренең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);»;

әлеге Тәртипкә кушымтаның 3 пунктындагы 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «4. | Сайлап алуда катнашучы оешма офшор компаниясе, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик заты капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый | булып тора/ улып тормый***». |

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесен төзегәндә устав фондын булдыруга һәм аның устав фондын арттыруга чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 21 октябрь, 992 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесен төзегәндә устав фондын булдыруга һәм аның устав фондын арттыруга

чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлап алуны үткәрү срокларын, заявкалар бирелә башлау яки кабул итү тәмамлану датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән иртәрәк була алмый);»;

9 пунктның бишенче абзацында «сайлап алуны үткәрү турында игълан урнаштырылган айга кадәрге айның беренче көненә карата» сүзләрен төшереп калдырырга;

15 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәләренең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);».

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына бәяләү эшчәнлегенә бәйле эксперт һәм консультация ярдәме күрсәтүне гамәлгә ашыру чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) максатларында коммерциягә карамаган оешмаларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш) Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 19 декабрь, 1104 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 19 ноябрь, 1104 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына бәяләү эшчәнлегенә бәйле эксперт һәм консультация ярдәме күрсәтүне гамәлгә ашыру чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) максатларында коммерциягә карамаган оешмаларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш) Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Субсидияләр турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

8 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлап алуны үткәрү срокларын, заявкалар бирелә башлау яки кабул итү тәмамлану датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән иртәрәк була алмый);»;

9 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министр-

лыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик заты капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;»;

10 пунктта:

бишенче абзацта «сайлап алуны үткәрү турында игълан урнаштырылган айга кадәрге айның беренче көненә карата» сүзләрен төшереп калдырырга;

егерме беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлап алуны үткәрү планлаштырыла торган айга кадәрге айның 1 нче көненә коммерциягә карамаган оешманың офшор компаниясе, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры (яки) турыдан-туры булмаган (өченче зат аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмавын раслый торган, коммерциягә карамаган оешма җитәкчесе тарафыннан кул куелган гарантия хатын;»;

15 пунктның беренче абзацында «җиңүчеләрне» сүзен «җиңүчене» сүзенә алмаштырырга;

21 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәләренең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин